**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 сентябрендәге 3975 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**кайбер карарларын гамәлдән чыккан дип**
**тану һәм үзгәрешләр кертү турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 7 маендагы 1934 номерлы «Казан шәһәренең “Муниципаль торак программалары дирекциясе” муниципаль унитар предприятиесе ябылу турында»гы, 2024 елның 13 маендагы 1978 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты карарларының гамәлдән чыгуын тану турында»гы карарлары кабул ителүгә бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының түбәндәге карарларын гамәлдән чыккан дип танырга:

1.1. 2023 елның 2 августындагы 2183 номерлы «Казан шәһәренең “Муниципаль торак программалары дирекциясе” муниципаль унитар предприятиесенең Бирюзовая урамындагы 1 номерлы торак йортта урнашкан фатирларны сату ысулын үзгәртү турында»;

1.2. 2023 елның 8 сентябрендәге 2615 номерлы «Казан шәһәренең “Муниципаль торак программалары дирекциясе” муниципаль унитар предприятиесенең Бирюзовая урамындагы 1 номерлы торак йортта урнашкан 65 фатирны сату ысулын үзгәртү турында»;

1.3. 2024 елның 1 апрелендәге 1239 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 2 августындагы 2183 номерлы “Казан шәһәренең «Муниципаль торак программалары дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесенең Бирюзовая урамындагы 1 номерлы торак йортта урнашкан фатирларны сату ысулын үзгәртү турында”гы, 2023 елның 8 сентябрендәге 2615 номерлы “Казан шәһәренең «Муниципаль торак программалары дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесенең Бирюзовая урамындагы 1 номерлы торак йортта урнашкан 65 фатирны сату ысулын үзгәртү турында”гы карарларына үзгәрешләр кертү хакында»;

1.4. 2023 елның 2 февралендәге 284 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 27 маендагы 2816 номерлы “Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән милекне сату тәртибе турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»;

1.5. 2023 елның 25 июлендәге 2087 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 27 маендагы 2816 номерлы “Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән милекне сату тәртибе турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында».

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 27 маендагы 2816 номерлы «Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән милекне сату тәртибе турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 5 декабрендәге 7015 номерлы, 2015 елның 12 октябрендәге 3703 номерлы, 2018 елның 18 июлендәге 4041 номерлы, 2019 елның 22 февралендәге 646 номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 2732 номерлы, 2020 елның 14 маендагы 1371 номерлы, 2021 елның 18 июнендәге 1533 номерлы, 2023 елның 2 февралендәге 284 номерлы, 2023 елның 25 июлендәге 2087 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән милекне сату тәртибе хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1.4 пункттан икенче абзацны төшереп калдырырга;

2.2. 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1. Муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән милекне сату унитар предприятиене устав белән билгеләнгән эшчәнлек алып бару мөмкинлегеннән мәхрүм итмәсә, әлеге милекне сату милекче ризалыгы белән рөхсәт ителә. Муниципаль унитар предприятиеләрнең хуҗалык карамагында булган милекне сату ачык аукцион сатулары уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла»;

2.3. 2.6 пунктны төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**